| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.12.2021 ел Менделеевск ш. № 862

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2018 елның 2 февралендә 60 номерлы карар белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә туры китереп Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елның 31 гыйнвары 16.00 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының административ бинасында түбәндәге адрес буенча: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19, актлар залы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү»проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

– комиссия рәисе - Зарипов Л. М. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм стратегик үсеш буенча беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы;

Санков М. А – - Татарстан Республикасы "Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе" муниципаль автоном учреждениесе башлыгы;

Хәбиров Р. З. – Татарстан Республикасы “Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе»муниципаль автоном учреждениесенең проектлау бүлеге башлыгы;

Антоновская Н. И. – Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

3. 2021 елның 29 декабреннән 2022 елның 29 гыйнварына кадәр «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү» проекты материалларына Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 (5 кат) адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең проектлау бүлегендә экспозиция оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр («Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең проектлау бүлеге башлыгы исеменә) түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 432650, Татарстан Республикасы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19

5. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга. http://Mendeleevsk.tatar.ru

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе " муниципаль автоном учреждениесенең проектлау бүлеге башлыгы Р. З.Хәбировка йөкләргә

Җитәкче: Р.И. Беляев

Килешенгән :
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

«ТР ММР инвестиция һәм инфраструктура
үсеше идарәсе " муниципаль автоном
учреждениесенең проектлау бүлеге башлыгы Р.З.Хабиров